**МИНИСТЕРСТВО ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

12.10.2015 № 728

г.Казань

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2015 елның 9 ноябрендә теркәлде, теркәү № 2973

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән
тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының
"Медицина оешмаларында йөклелекнең иртә срокларында
(унике атнага кадәр) исәпкә баскан, оешмалар бетерелүгә,
физик затларның шәхси эшкуар сыйфатындагы
эшчәнлекләрен туктатуына, хосусый практика белән
шөгыльләнүче нотариусларның үз вәкаләтләрен
туктатуына һәм адвокат статусы туктатылуга бәйле
рәвештә, шулай ук һөнәри эшчәнлекләре
федераль законнар нигезендә дәүләт теркәвенә
алынырга һәм (яки) лицензияләнергә тиеш булган
башка физик затларның үз эшчәнлекләрен
туктатуына бәйле рәвештә, аларны билгеләнгән тәртиптә
эшсез дип тану көненнән алдан килгән унике ай эчендә
эштән азат ителгән хатын-кызларга
бер тапкыр түләнә торган пособие билгеләү буенча
дәүләт хезмәте күрсәтүнең
административ регламентын раслау хакында"
02.02.2015 ел, № 64 боерыгы белән расланган
Медицина оешмаларында йөклелекнең
иртә срокларында (унике атнага кадәр)
исәпкә баскан, оешмалар бетерелүгә,
физик затларның шәхси эшкуар сыйфатындагы
эшчәнлекләрен туктатуына, хосусый практика белән
шөгыльләнүче нотариусларның үз вәкаләтләрен туктатуына
һәм адвокат статусы туктатылуга бәйле рәвештә,
шулай ук һөнәри эшчәнлекләре федераль законнар нигезендә
дәүләт теркәвенә алынырга һәм (яки) лицензияләнергә
тиеш булган башка физик затларның
үз эшчәнлекләрен туктатуына бәйле рәвештә,
аларны билгеләнгән тәртиптә
эшсез дип тану көненнән алдан килгән унике ай эчендә
эштән азат ителгән хатын-кызларга
бер тапкыр түләнә торган пособие билгеләү буенча
дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына
үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында” 02.11.2010 ел, № 880 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибенә үзгәрешләр кертү турында” 17.04.2015 ел, № 259 карары чыгуга бәйле рәвештә **боерык бирәм:**

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының “Медицина оешмаларында йөклелекнең иртә срокларында (унике атнага кадәр) исәпкә баскан, оешмалар бетерелүгә, физик затларның шәхси эшкуар сыйфатындагы эшчәнлекләрен туктатуына, хосусый практика белән шөгыльләнүче нотариусларның үз вәкаләтләрен туктатуына һәм адвокат статусы туктатылуга бәйле рәвештә, шулай ук һөнәри эшчәнлекләре федераль законнар нигезендә дәүләт теркәвенә алынырга һәм (яки) лицензияләнергә тиеш булган башка физик затларның үз эшчәнлекләрен туктатуына бәйле рәвештә, аларны билгеләнгән тәртиптә эшсез дип тану көненнән алдан килгән унике ай эчендә эштән азат ителгән хатын-кызларга бер тапкыр түләнә торган пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау хакында” 02.02.2015 ел, № 64 боерыгы белән расланган Медицина оешмаларында йөклелекнең иртә срокларында (унике атнага кадәр) исәпкә баскан, оешмалар бетерелүгә, физик затларның шәхси эшкуар сыйфатындагы эшчәнлекләрен туктатуына, хосусый практика белән шөгыльләнүче нотариусларның үз вәкаләтләрен туктатуына һәм адвокат статусы туктатылуга бәйле рәвештә, шулай ук һөнәри эшчәнлекләре федераль законнар нигезендә дәүләт теркәвенә алынырга һәм (яки) лицензияләнергә тиеш булган башка физик затларның үз эшчәнлекләрен туктатуына бәйле рәвештә, аларны билгеләнгән тәртиптә эшсез дип тану көненнән алдан килгән унике ай эчендә эштән азат ителгән хатын-кызларга бер тапкыр түләнә торган пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.3.2 пунктның 1 пунктчасын “Үзәк бүлекләрендә” дигән сүзләрдән соң “. Мәгълүмат стендларында урнаштырыла торган мәгълүмат дәүләт хезмәте күрсәтү турында бу Регламентның 1.3.1, 2.1, 2.3, 2.4, 2.5, 2.8, 2.10, 2.11, 5.1 пунктларында (пунктчаларында) булган белешмәләрне үз эченә ала.” дигән сүзләр белән тулыландырырга;

1.4 пунктның тугызынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында” 02.11.2010 ел, № 880 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан

дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе (алга таба – № 880 Тәртип) (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнарының норматив актлары җыентыгы, 2010, № 46, 2144 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);";

1.5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"1.5. Бу Регламентта түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр кулланыла:

техник хата – дәүләт хезмәте күрсәтүче орган тарафыннан җибәрелгән һәм документка (дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсенә) кертелгән мәгълүматларның мәгълүматлар керткәндә нигез булып торган документлардагы мәгълүматларга туры килмәвенә китергән хата (ялгыш язу, басмада ялгышлык, грамматик яки арифметик хата);

дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урыны – муниципаль районнарның авыл җирлекләрендә документларны кабул итү һәм бирү, гариза бирүчеләргә консультацияләр үткәрү "тәрәзә"се.

Бу Регламентта дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза (алга таба – гариза) төшенчәсе № 210-ФЗ Федераль законның 2 статьясының 1 пунктында күздә тотылган дәүләт хезмәтен күрсәтү турында рәсми мөрәҗәгатьне аңлата. Гаризаның киңәш ителә торган формасы бу Регламентка 1 нче кушымтада китерелгән.";

2.15 пунктта;

"Стандартка карата таләпләр эчтәлеге" дигән графада:

унбишенче абзацта "2015 елда" дигән сүзләрне төшереп калдырырга;

түбәндәге эчтәлектәге уналтынчы – унсигезенче абзацлар белән тулыландырырга:

"Дәүләт хезмәте күрсәткәндә гариза бирүче белән Үзәк бүлеге белгеченең бер тапкыр аралашуы 15 минуттан артмый.

Дәүләт хезмәте, дәүләт хезмәте күрсәтүгә гариза бирүне кертеп, күпфункцияле үзәк аша, дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урыннарында күрсәтелми.

Дәүләт хезмәте күрсәтүнең барышы турындагы мәгълүмат гариза бирүче тарафыннан http://mtsz.tatarstan.ru сайтыннан, Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталыннан алынырга мөмкин.";

"Дәүләт хезмәтен яки таләпне билгеләүче норматив акт" графасында "№ 880 ТР МК карарының" дигән сүзләрне "№ 880 Тәртипнең" дигән сүзләр белән алмаштырырга;

"Стандартка карата таләпләр эчтәлеге" дигән графаның 2.16 пунктында:

икенче абзацта "2015 елда" дигән сүзләрне төшереп калдырырга;

дүртенче абзацны төшереп калдырырга;

3 нче бүлекнең атамасын "күпфункцияле үзәкләрдә" дигән сүзләрдән соң ", дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урыннарында" дигән сүзләр белән тулыландырырга;

3.5 пунктны "күпфункцияле үзәк" дигән сүзләрдән соң "һәм дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкнең ерактагы

эш урыннары" дигән сүзләр белән тулыландырырга;

Регламентны түбәндәге эчтәлектәге 3.6 – 3.6.3 пунктлар белән тулыландырырга:

"3.6. Техник хаталарны төзәтү.

Бер тапкыр бирелә торган пособие билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турындагы карарны үзгәртеп рәсмиләштерү бер тапкыр бирелә торган пособие билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турындагы карарда җибәрелгән техник хаталарны (ялгыш язулар, басмада ялгышлыклар, грамматик яки арифметик хаталар) бетерүгә бәйле рәвештә башкарыла.

Бер тапкыр бирелә торган пособие билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турындагы карарны үзгәртеп рәсмиләштерү алучыга дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе буларак тапшырылган техник хаталы документны (андый документ бирелгән очракта) кушып теркәлгән гариза (гаризаның киңәш ителә торган формасы бу Регламентка 6 нчы кушымтада китерелгән) нигезендә башкарыла.

3.6.1. Үзәк бүлеге белгече:

техник хатаны төзәтү турындагы гаризаны кабул итә һәм гражданнарның мөрәҗәгатьләрен теркәү журналында (бу Регламентка 2 нче кушымта) терки;

бер тапкыр бирелә торган пособие билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар проектын үзгәртеп рәсмиләштерә;

бер тапкыр бирелә торган пособие билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында үзгәртеп рәсмиләштерелгән карар проектын Үзәк бүлеге җитәкчесенә имза куюга җибәрә.

Бу пункт билгели торган процедуралар гариза теркәлгән моменттан башлап бер көн эчендә үтәлә.

Процедура нәтиҗәсе: техник хатаны төзәтү турында кабул ителгән, теркәлгән гариза, бер тапкыр бирелә торган пособие билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында үзгәртеп рәсмиләштерелгән, Үзәк бүлеге җитәкчесенә имза куюга җибәрелгән карар проекты.

3.6.2. Үзәк бүлеге җитәкчесе бер тапкыр бирелә торган пособие билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында үзгәртеп рәсмиләштерелгән карарны имзалый һәм Үзәк бүлеге белгеченә җибәрә.

Бу пункт билгели торган процедура бер тапкыр бирелә торган пособие билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турындагы карар проекты имза куюга җибәрелгән моменттан башлап бер көн эчендә үтәлә.

Процедура нәтиҗәсе: бер тапкыр бирелә торган пособие билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында имзаланган үзгәртеп рәсмиләштерелгән карар.

3.6.3. Үзәк бүлеге белгече бер тапкыр бирелә торган пособие билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында үзгәртеп рәсмиләштерелгән карар хакында, гаризада күрсәтелгән ысул белән, гариза бирүчегә хәбәр итә.

Бу пункт билгели торган процедура моннан алдагы процедура тәмамланган моменттан башлап бер көн эчендә үтәлә.

Процедура нәтиҗәсе: бер тапкыр бирелә торган пособие билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында үзгәртеп рәсмиләштерелгән карар хакында гариза бирүчегә хәбәр итү.";

5 бүлекнең атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:


“5. Үзәкнең дәүләт хезмәте күрсәтүче бүлегенең, шулай ук аның вазыйфаи затларының һәм хезмәткәрләренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибе”;

5.3 пунктның икенче абзацын "күпфункцияле үзәк," дигән сүзләрдән соң “дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче үзәкнең ерактагы эш урыннары аша,” дигән сүзләр белән тулыландырырга;

Регламентка 4 нче һәм 5 нче кушымталарны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:


“Медицина оешмаларында йөклелекнең иртә срокларында (унике атнага кадәр) исәпкә баскан, оешмалар бетерелүгә, физик затларның шәхси эшкуар сыйфатындагы эшчәнлекләрен туктатуына, хосусый практика белән шөгыльләнүче нотариусларның үз вәкаләтләрен туктатуына һәм адвокат статусы туктатылуга бәйле рәвештә, шулай ук һөнәри эшчәнлекләре федераль законнар нигезендә дәүләт теркәвенә алынырга һәм (яки) лицензияләнергә тиеш булган башка физик затларның үз эшчәнлекләрен туктатуына бәйле рәвештә, аларны билгеләнгән тәртиптә эшсез дип тану көненнән алдан килгән унике ай эчендә эштән азат ителгән хатын-кызларга бер тапкыр бирелә торган пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 4 нче кушымта


**Гариза бирүче шәхсән мөрәҗәгать иткәндә, яки гариза һәм документларны почта аша җибәргәндә, медицина оешмаларында йөклелекнең иртә срокларында (унике атнага кадәр) исәпкә баскан, оешмалар бетерелүгә, физик затларның шәхси эшкуар сыйфатындагы эшчәнлекләрен туктатуына, хосусый практика белән шөгыльләнүче нотариусларның үз вәкаләтләрен туктатуына һәм адвокат статусы туктатылуга бәйле рәвештә, шулай ук һөнәри эшчәнлекләре федераль законнар нигезендә дәүләт теркәвенә алынырга һәм (яки) лицензияләнергә тиеш булган башка физик затларның үз эшчәнлекләрен туктатуына бәйле рәвештә, аларны билгеләнгән тәртиптә эшсез дип тану көненнән алдан килгән унике ай эчендә эштән азат ителгән хатын-кызларга бер тапкыр бирелә торган пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү гамәлләре эзлеклелегенең блок-схемасы**


Мөрәҗәгать итүче
Гаризаны һәм, Регламентның 2.5 пунктына туры китереп, документларны шәхсән, почта аша тапшыра
Гариза һәм документлар
Үзәк бүлеге белгече
Документларны кабул итеп алудан баш тартуга бу Регламентның 2.8 пунктында күздә тотылган нигезләр булуын тикшерә
Документлар таләпләргә туры килә
Әйе
Юк
Үзәк бүлеге белгече
Гаризаны кабул итә, гражданнарның мөрәҗәгатьләрен теркәү журналында терки, гариза бирүчегә документлар кабул ителгән көнне, бирелгән керүче номерны күрсәтеп, расписка тапшыра, гариза һәм документларны почта аша алганда, гаризаны теркәү датасы турында хәбәрнамә җибәрә – гариза һәм документлар кергән көнне, мәгълүматлар сорап, рәсми мөрәҗәгать формалаштыра – 1 көн
Кабул ителгән, теркәлгән гариза һәм документлар
Гаризаны теркәүгә каршылыклар булу турында гариза бирүчегә хәбәр итә һәм аңа документларын кире кайтара – 1 эш көне
Кире кайтарылган документлар
Үзәк бүлеге белгече
Баш тарту өчен Регламентның 2.9 пунктында күздә тотылган нигезләр булуын тикшерә, бер тапкыр бирелә торган пособие билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар проектын рәсмиләштерә – 7 көн, ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр булмаганда – 2 көн
Бер тапкыр бирелә торган пособие билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар проекты
Үзәк бүлеге җитәкчесе
Бер тапкыр бирелә торган пособие билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар проектын карап тикшерә һәм имзалый – 1 көн
Бер тапкыр бирелә торган пособие билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында имзаланган карар
Үзәк бүлеге белгече
Бер тапкыр бирелә торган пособие билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында кабул ителгән карар хакында гариза бирүчегә хәбәр итә. “Дело”ны формалаштыра – 1 көн
Бер тапкыр бирелә торган пособие билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында кабул ителгән карар хакында хәбәр итү
Үзәк бүлеге белгече
Гариза бирүчедән техник хатаны төзәтү турында гариза кергән очракта, бер тапкыр бирелә торган пособие билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар проектын үзгәртеп рәсмиләштерә – 1 көн
Бер тапкыр бирелә торган пособие билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында үзгәртеп рәсмиләштерелгән карар проекты
Үзәк бүлеге җитәкчесе
Бер тапкыр бирелә торган пособие билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында үзгәртеп рәсмиләштерелгән карарны карап тикшерә һәм имзалый - 1 көн
Бер тапкыр бирелә торган пособие билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында үзгәртеп рәсмиләштерелгән имзаланган карар
Үзәк бүлеге белгече
Бер тапкыр бирелә торган пособие билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында үзгәртеп рәсмиләштерелгән карар хакында гариза бирүчегә хәбәр итү - 1 көн
Бер тапкыр бирелә торган пособие билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында үзгәртеп рәсмиләштерелгән карар хакында хәбәрнамә

Медицина оешмаларында йөклелекнең иртә срокларында (унике атнага кадәр) исәпкә баскан, оешмалар бетерелүгә, физик затларның шәхси эшкуар сыйфатындагы эшчәнлекләрен туктатуына, хосусый практика белән шөгыльләнүче нотариусларның үз вәкаләтләрен туктатуына һәм адвокат статусы туктатылуга бәйле рәвештә, шулай ук һөнәри эшчәнлекләре федераль законнар нигезендә дәүләт теркәвенә алынырга һәм (яки) лицензияләнергә тиеш булган башка физик затларның үз эшчәнлекләрен туктатуына бәйле рәвештә, аларны билгеләнгән тәртиптә эшсез дип тану көненнән алдан килгән унике ай эчендә эштән азат ителгән хатын-кызларга йөклелек һәм бала тудыру пособиесе билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 5 нче кушымта

**Гариза бирүче Татарстан Республикасы Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша мөрәҗәгать иткәндә, медицина оешмаларында йөклелекнең иртә срокларында (унике атнага кадәр) исәпкә баскан, оешмалар бетерелүгә, физик затларның шәхси эшкуар сыйфатындагы эшчәнлекләрен туктатуына, хосусый практика белән шөгыльләнүче нотариусларның үз вәкаләтләрен туктатуына һәм адвокат статусы туктатылуга бәйле рәвештә, шулай ук һөнәри эшчәнлекләре федераль законнар нигезендә дәүләт теркәвенә алынырга һәм (яки) лицензияләнергә тиеш булган башка физик затларның үз эшчәнлекләрен туктатуына бәйле рәвештә, аларны билгеләнгән тәртиптә эшсез дип тану көненнән алдан килгән унике ай эчендә эштән азат ителгән хатын-кызларга бер тапкыр бирелә торган пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү гамәлләре эзлеклелегенең блок-схемасы**





”

Регламентны түбәндәге эчтәлектәге 6 нчы кушымта белән тулыландырырга:

“Медицина оешмаларында йөклелекнең иртә срокларында (унике атнага кадәр) исәпкә баскан, оешмалар бетерелүгә, физик затларның шәхси эшкуар сыйфатындагы эшчәнлекләрен туктатуына, хосусый практика белән шөгыльләнүче нотариусларның үз вәкаләтләрен туктатуына һәм адвокат статусы туктатылуга бәйле рәвештә, шулай ук һөнәри эшчәнлекләре федераль законнар нигезендә дәүләт теркәвенә алынырга һәм (яки) лицензияләнергә тиеш булган башка физик затларның үз эшчәнлекләрен туктатуына бәйле рәвештә, аларны билгеләнгән тәртиптә эшсез дип тану көненнән алдан килгән унике ай эчендә эштән азат ителгән хатын-кызларга йөклелек һәм бала тудыру пособиесе билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 6 нчы кушымта

РЦМП (КВ) №_____ бүлегенә
________________________ муниципаль районындагы (шәһәрдәге)

Техник хатаны төзәтү турында
гариза

Мин,____________________________________________________________________ ,
*(гариза бирүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме тулысынча күрсәтелә)*
түбәндәге адрес буенча яшим: ____________________________________________
_______________________________________________________________________________
*(индексын күрсәтеп, гариза бирүченең почта адресы, телефоны, электрон адресы)*
_______________________________________________________________________________
*(гариза бирүченең шәхесен таныклаучы документ атамасы, аның сериясе, номеры, бирү көне,*
_______________________________________________________________________________
*(документны биргән орган атамасы)*

Социаль ярдәм чараларын билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турындагы
_______________ № _______________
карар датасы карар номеры
карарда җибәрелгән техник хатаны ___________________________________
_______________________________________________________________________________
_______________________________________________________________________________
______________________________________________________________төзәтүне үтенәм.
Дәүләт хезмәте күрсәтү (күрсәтүдән баш тарту) турында үзгәртеп

рәсмиләштерелгән карарны ____________________________________________
__________________________________________________________________________
(язмача, электрон почта белән, ТР Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталындагы шәхси кабинетка)
алырга риза.
“__” ________ 20__ ел ______________ ____________________________
(гариза бирүче имзасы) (тулы имза)”.

**Министр** **Э.Ә.Зарипова**